ШИМБӘ
27
МАРТ
1943 ел.
№ 68 (6790)
Аерым номеры 20 тиен.

БАРЛЫК ИЛЛӘРНЕҢ ПРОЛЕТАРИЙЛАРЫ, БЕРЛӘШЕГЕЗ!

КЫЗЫЛ ТАТАРСТАН

ВКП(б) ның ТАТАРСТАН ӨЛКӘ һӘМ КАЗАН ШӘһӘР КОМИТЕТЛАРЫ, ТАССР ВЕРХОВНЫЙ СОВЕТЫ һӘМ ХЕЗМӘТ ИЯЛӘРЕ ДЕПУТАТЛАРЫНЫҢ КАЗАН ШӘһӘР СОВЕТЫ ОРГАНЫ.

КЫЗЫЛ АРМИЯ БАШ КОМАНДОВАНИЕСЕНЕҢ МАХСУС ФОНДЫНА

Совет кешесе явыз дошманны тар-мар итүгә, изге җирләребезне немец-фашист илбасарлардан чистартуга булган үзенең көчле омтылышын һәм какшамас ышанычын героик хезмәт белән беркетә. Фронт өчен, данлыклы Кызыл Армиябез өчен коралларны, сугыш припасларын, азык продуктларын никадәр кирәк булса, шул кадәр җитештерүдә ул һичбер нәрсәне кызганмый.

Дәүләт планнарын арттырып үтәү, Кызыл Армия Баш Командованиесенең махсус фондын төзү өчен көрәшкә чакырып Куйбышев шәһәре хезмәт ияләре тарафыннан башланып җибәрелгән гүзәл инициатива хәзер илебезнең барлык почмакларына да киң таралды һәм ул инде куәтле патриотик хәрәкәт булып әверелде, массовый төс алды.

Партоешма секретаре урынбасары иптәш Закиров булган Н-че завод, бу хәрәкәткә кушылып, апрель ае планын 105 процентка үтәргә һәм ярты еллык планны 25 нче июньгә төгәлләргә, чималга 10 процент экономия ясарга, шушы ук вакыт эчендә производствода рационализация чаралары үткәрү исәбенә 800.000 сум экономия ясарга йөкләмә алды. Баш инженеры иптәш Касаткин булган завод 1 нче Майга кадәр яңа төр изделие эшләп чыгаруны үзләштерергә булды. Бу завод планнан тыш өстәмә рәвештә ике дивизия һәм биш полкны коралландырырга җитәрлек продукция эшләп чыгару өчен көрәшә.

Мондый мисалларны күпләп китерергә мөмкин.

Совет патриотлары йөкләмә алып кына, сүз биреп кенә калмыйлар. Кызыл Армия Баш Командованиесенең махсус фондын төзү эшенең гаять җитди бурыч икәнлеген тулысынча аңлап, алар үз өсләренә алган йөкләмәләрен намус белән үтәү һәм арттырып үтәү өчен барлык көчләрен һәм белемнәрен биреп эшлиләр. Күпләр өчен характерлы булган бер генә мисал китерү дә җитә. Баш инженеры иптәш Корнеев булган завод март һәм апрель айларында планнан тыш ике партия изделие эшләп чыгарырга һәм аны Кызыл Армиябезнең Баш Командованиесе фондына тапшырырга йөкләмә алган иде. Бу йөкләмә, коллективның гаять зур күтәренкелек белән эшләве нәтиҗәсендә, срогыннан элек, март аенда ук тулысынча үтәлде. Хәзер инде завод эшчеләре һәм инженер-техниклары Баш Командование фондына тагын да өстәмә рәвештә яңа изделиеләр җитештереп тапшыру өчен үз-үзләрен аямыйча эшлиләр.

Хезмәт фронтында һәр ел саен киң колач алып җәелә торган Беренче Май алды ярышы быел, сугыш шартларында, әнә шулай изге максатка юнәлтелгән гүзәл яңа формалар белән тагын да тулыланды. Безнең героик Кызыл Армиябезнең бөек полководец иптәш Сталин җитәкчелегендәге Баш Командованиесе өчен гаять куәтле булган махсус фонд туплана. Бу фонд—дәһшәтле самолетлар, танклар, пулеметлар, минометлар, сугыш припаслары һ. б. — ерткыч дошман өстенә өстәмә рәвештә үлем уты булып явар. һәм бу утның көчен тагын да арттыру, дошманны ниһаять тәмам тар-мар итү өчен, вакытны, көчне, һичбер нәрсәне аямыйча эшләргә, эшләргә һәм эшләргә кирәк. Май алды ярышына йомгаклар ясаганда, гомуми сүзләргә, ышандыруларга карап түгел, төзелгән договорлар, ярышучы эшчеләрнең, коллективларның формаль саны белән түгел, бәлки производство программаларының ничә процентка арттырылып үтәлүенә, материалларга, чималга, ягулыкка, электр энергиясенә күпме экономия ясалган булуга, хезмәт җитештерүчәнлеге ничә процентка күтәрелгән булуга һәм нәтиҗәдә, Кызыл Армиянең Баш Командованиесе фондына конкрет саннар белән исәпләнә торган күпме өстәмә продукция тапшырылган булуына карап бәя бирелергә тиеш. Моны һәрбер партия, комсомол, пофсоюз оешмасы җитәкчеләре, һәрбер хуҗалыкчы, һәрбер инженер һәм техник, һәрбер эшченык исендә тотарга тиеш.

Дәүләт планнарын арттырып үтәү, Кызыл Армия Баш Командованиесенең махсус фондын куәтле сугыш көче итеп төзү өчен көрәшне тагын да киңрәк җәелдерү, Беренче Май алды ярышын әнә шул конкрет бурычны үтәүгә юнәлдерү—барлык предприятиеләрнең, барлык хезмәт ияләренең бүгенге иң мактаулы бурычы ул.

Совет Информбюросыннан

26 нчы МАРТТАГЫ ИРТӘНГЕ БЕЛДЕРҮ

26 нчы мартка каршы төндә безнең гаскәрләр элекке юнәлешләрдә сугышлар алып бардылар.

*Көнбатыш фронтта безнең гаскәрләр үзләре алган позицияләргә ныгып урнаштылар, ә гаскәрләренең бер өлеше һөҗүм сугышлары алып барды. Н-че часть подразделениеләре дошманның ныгытмаларына бәреп керделәр һәм аларны алдылар. Бер ротага якын немец пехотасы, дошманның 3 орудиесе юк ителде, 16 ДЗОТ ы һәм блиндажы җимертелде.

*Белгород районында дошманның сан ягыннан өстен булган көчләре безнең подразделениеләрне бераз кысрыкладылар һәм халык яши торган 2 пунктны алдылар. Н-че часть, үзенең көчләрен яңадан оештырып, төнлә белән гитлерчыларны бу пунктлардан бәреп чыгарды һәм элекке хәлне кайтарды. 100 дән артык немец солдатлары һәм офицерлары юк ителде. Дошманның 4 орудиесе, 70 автоматы, берничә пулеметы һәм башка төрле сугыш милекләре кулга төшерелде.

*Кубаньда Н-че берләшмә частьлары алга бардылар һәм халык яши торган берничә пунктны алдылар. Безнең бер частебызның сугышчылары су чиге аркылы кичеп, дошманга кинәт һөҗүм ясадылар. Немецлар каршылык күрсәтергә маташып карадылар, ләкин 200 дән артык солдатлары һәм офицерлары үтерелгәннән соң ашыгыч рәвештә чигенделәр. Дошманның 7 пулеметы, бер артиллерия һәм 4 миномет батареясы юк ителде. Икенче бер участокта Н-че часть подразделениеләре, халык яши торган бер пунктны алган чакта, 4 орудие, эре калибрлы 7 пулемет, 180 винтовка, 20 автомашина һәм сугыш припаслары склады кулга төшерделәр.

*Чугуевтан төньяктарак безнең частьлар дошманның пехотасына һәм танкларына каршы сугышлар алып бардылар. Н-че часть подразделениеләре бер көн эчендә немецларның 2 танкысын сафтан чыгардылар һәм 160 гитлерчыны юк иттеләр. Икенче бер участокта капитан Бондырев командалыгындагы бер группа разведчиклар дошман кулындагы бер авылга бәреп керделәр. Лейтенант Богачев, туры атып, 3 немец солдатын һәм бер офицерны үтерде, ә патроннары беткәч, мылтык түтәсе белән бәреп тагын 3 немецны үтерде. Башка разведчиклар 17 гитлерчыны кырып ташладылар.

*Ленинградка килү юлларында булган һава сугышларында безнең очучылар 25 нче мартта немецларның 5 самолетын бәреп төшерделәр. Шуның өстенә зенит артиллериясе уты белән дошманның 8 самолеты юк ителде һәм 3 самолеты зарарланды.

*Ленинград өлкәсенең бер районында хәрәкәт итүче партизаннар отряды немецларның халык яши торган бер пункттагы гарнизонына һөҗүм иткән һәм 26 гитлерчыны кырып ташлаган. Икенче бер отрядның бер группа партизаннары немецларның бер хәрби эшелонын юлдан чыгарганнар. Һәлакәт нәтиҗәсендә бер паровоз, 9 вагон һәм 2 платформа җимерелгән.

*Курск өлкәсенең Льгов районында оккупация вакытында немец-фашист кабахәтләр берничә мең кешене газаплаганнар һәм үтергәннәр. Чигенер алдыннан гитлерчылар бигрәк тә котырынганнар. Бандитлар төрле вакытларда немецлар тарафыннан кулга алынып төрмәгә ябылган күп кешеләрне суйганнар. Ольшанка авылында немецлар 52 кешене, Орловка авылында 147 кешене ерткыч төстә газаплаганнар һәм атканнар. Ләкин совет кешеләренең батырлыгын бу коточкыч газаплаулар сындыра алмаган. Алар оккупантлар алдында тез чүкмәгәннәр һәм немецларга баш имәгәннәр. Совет патриотлары геройлар булып үлгәннәр. Палачлар Ефросиния Гришаеваны озак газаплаганнар. Аннардан шәһәрдә калган совет активистлары турында мәгълүматлар алырга тырышканнар. 50 яшьлек бу хатын барлык газаплауларны нык торып үткәргән һәм гитлерчыларга бер нәрсә дә әйтмәгән. Немецлар тарафыннан авыр яраланган колхозчы Жарких, актык көчен җыеп, «Яшәсен совет ватаны! Үлем немец илбасарларга!» дип кычкырган.

26 нчы МАРТТАГЫ КИЧКЕ БЕЛДЕРҮ

26 нчы мартта безнең гаскәрләр элекке юнәлешләрдә сугышлар алып бардылар.

* 25 нче мартта безнең авиация частьлары фронтның төрле участокларында немецларның гаскәрләр һәм йөкләр төялгән 100 гә якын автомашинасын юк иттеләр яки зарарладылар, 2 сугыш припаслары складын шартлаттылар, 5 кыр һәм зенит артиллериясе батареясының утын бастырдылар, бер тимер юл составын җимерделәр.

* Көнбатыш фронтта безнең гаскәрләр аерым участокларда үзләре алган позицияләрне яхшырту өчен сугышлар алып бардылар. Н-че часть сугышчылары дошман оборонасының көчле итеп ныгытылган ике пунктын алдылар. Бу пунктлар өчен булган сугышларда 200 дән артык немец солдатлары һәм офицерлары юк ителде. Дошманның 4 орудиесе, 20 пулеметы, танкка каршы ата торган 5 мылтыгы һәм башка трофейлар кулга төшерелде.

* Белый шәһәреннән көньяктарак безнең частьлар халык яши торган берничә пунктны алдылар. Бер участокта немецлар халык яши торган һәм көчле итеп ныгытылган оборона узелына әйләндерелгән бер пунктны бик тырышып сакладылар. Командиры иптәш Петренко булган частьның 4 группа сугышчылары урман аркылы үтеп һәм елганы кичеп, немецларның тылына төштеләр. Алдан билгеләнгән сигнал буенча совет сугышчылары дошманга тылдан удар ясадылар. Дошманның ут астыннан чыгарга маташулары барысы да уңышсыз чыкты. 300 ләп солдаттан һәм офицердан торган дошман гарнизоны юк ителде. Трофейлар кулга төшерелде.

* Белгород районында немецларның бер батальон пехотасы, танклар ярдәме белән, бер урында совет гаскәрләре урнашкан җиргә үтеп керергә маташтылар. Безнең частьлар бу һөҗүмне кире кайтардылар, 100 дән артык гитлерчы юк ителде һәм немецларның 2 танкысы яндырылды. 4 пулемет һәм 3 миномет кулга төшерелде.

* Чугуевтан төньяктарак безнең гаскәрләр дошман танкларының һәм пехотасының күп санлы атакаларын кире кайтардылар. Ике көн дәвам иткән сугышларда Н-че танк часте немецларның 42 танкысын һәм бер батальонга якын пехотасын юк итте. Әһәмиятле бер биеклек өчен бик каты сугышлар барды. Безнең сугышчылар, барлык төр кораллардан ут ачып, гитлерчыларның 4 атакасын кире кайтардылар һәм дошманның 2 самоход орудиесен, бер миномет батареясын һәм бер ротага якын пехотасын юк иттеләр.

*Киев өлкәсенең бер районында хәрәкәт итүче партизаннар отряды 1 нче марттан 20 сенә кадәр булган сугышларда 380 немец-фашист оккупантны кырып ташлаган. Күп кенә пулеметлар, автоматлар, винтовкалар һәм патроннар кулга төшерелгән. Шул ук вакыт эчендә партизаннар 12 күперне шартлатканнар һәм дошманның бер хәрби эшелонын юлдан чыгарганнар. 34 вагон һәм платформалар җимерелгән. Һәлакәт вакытында берничә дистә гитлерчы үлгән һәм яралангән.

*Немецларның 58 нче пехота дивизиясенең 220 нче полкыннан үзе теләп плен бирелгән солдат Рихард В. болай диде: «Февраль ахырында Псковтагы хәрби төрмәдә безнең полкның 30 солдатын аттылар. Бу солдатлар фронтта чакта кораллары белән бергә руслар ягына чыгарга булганнар. Билгеләнгән көнне бу турыда кемдер обер-лейтенантка белдергән. Шуннан соң кулга алулар башланган. 17 кеше качарга өлгергән, ә калганнары коралсызландырылган һәм Псков төрмәсенә җибәрелгән. Атылганнар арасында 19 поляк, 9 немец, бер эльзаслы француз һәм бер чех бар».

*Немец-фашист кабахәтләр Ленинград өлкәсенең Сево авылында граждан халкын ерткыч төстә җәзалаганнар. Фашист бандитлар 40 колхозчыны, шул исәптән күп кенә хатын-кызларны һәм балаларны атканнар. Гитлерчы ерткычлар колхозчы Васильевның 9 кешедән торган семьясын, колхозчы Капитонов һәм Михайлов семьяларын тереләй яндырганнар.

*Франциянең Туль шәһәреннән ерак түгел генә азат укчылар немецлар отрядына һөҗүм иткәннәр. Ике арада башланган сугышта 28 гитлерчы үтерелгән һәм яраланган. Омнкурда Франция патриотлары немецларның сугыш материаллары төялгән бер эшелонын шартлатканнар.

БАЛЫК ТОТУ КОНВЕНЦИЯСЕНЕҢ СРОГЫН 1943 НЧЕ ЕЛГА ОЗАЙТУ ТУРЫНДА СОВЕТ—ЯПОНИЯ ПРОТОКОЛЫНА КУЛ КУЕЛУГА КАРАТА

Шушы елның 25 нче мартында, Куйбышев шәһәрендә булган сөйләшүләр нәтиҗәсендә. Чит Ил Эшләре Халык Комиссары урынбасары иптәш С. А. Лозовский һәм Япониянең СССР дагы илчесе Н. Сато әфәнде балык тоту турында 1928 нче елны төзелгән конвенциянең срогын 1943 нче елга озайту турындагы протоколга кул куйдылар һәм бу мәсьәлә буенча ноталар алмашу булды.

Мәгълүм ки, балык тоту турындагы 1928 нче елгы конвенциянең срогы 1936 нчы елның маенда ук тәмам булган иде. Балык тоту турында яңа конвенция төзелмәгәнлектән шул вакыттан башлап 1928 нче елгы конвенция, СССР һәм Япония хөкүмәтләре арасындагы килешү буенча, ел саен бер елга озайтылып килгән иде. Мәсәлән, балык тоту турындагы 1928 нче елгы конвенциянең срогы 1936 нчы елның калган өлешенә озайтылган иде һәм шуннан соң 1937, 1938, 1939, 1940, 1941 һәм 1942 нче елларга тагын ел саен озайтылып килде.

Совет-Япония протоколы һәм шушы елның 25 нче мартында кул куелган ноталар нигезендә, үткән елны булган килешү буенча билгеләнгән барлык шартлар 1943 нче елга да сакланып калалар. Тик шушындый бер үзгәреш кенә кертелә, Япониянең балык промышленниклары алтынлата аренда түләве керткән чакта үткән елгы килешү буенча билгеләнгән 4 процент урынына 5 процент күләмендә өстәмә сумма түлиләр.

ӘҺӘМИЯТ ҺӘМ КАЙГЫРТУЧАНЛЫК

Максим Горький исемендәге заводның профсоюз оешмасы кызылармеец семьяларына ярдәм күрсәтү буенча быел шактый гына эшләр башкарды. Беркайда да эшләми торган 200 семьяның материаль-көнкүреш хәле тикшерелде. 6 семья яңа квартирага күчерелде. 245 фронтовикның балалары бакчага урнаштырылдылар. Завод комитеты соңгы бер ел эчендә фронтовик семьяларына 50.000 сумнан артыграк акчалата ярдәм бирде. Күп кенә семьялар промтоварлар һәм аяк киемнәре белән тәэмин ителделәр. Хәзер мәктәп яшендәге балалар өчен аерым ашханә ачу чаралары күрелә.

Кызылармеец семьяларының сорауларын, аларның бигрәк тә нәрсәгә мохтаҗ булуларын якыннанрак өйрәнү теләге белән завод комитеты барлык фронтовик семьяларының материаль-көнкүреш шартларын тикшерү эше алып бара. Бу эшкә профсоюз активистлары һәм комсомолецлар тартылды.

Шушы көннәрдә заводта фронтовик семьялары өчен «Агымдагы хәл һәм безнең бурычлар» дигән темага лекция укылачак. Соңыннан кино-картина күрсәтелә һәм концерт биреләчәк.

М. ШВАРЦЕР.

Гайҗан бабай самолеты

I.

Гайҗан бабай кайтып чишенде дә,
Чәй түренә менеп утырды
Һәм карчыгын алып каршысына,
Бик дәртләнеп сүзгә тотынды:

—Бер киңәш бар сиңа, Карчык-
жамал,
Ни әйтерсең, нәрсә диерсең;
Бик зур эшкә ният итсәм әгәр,
Ниндиерәк җавап бирерсең?

— Сөйләп кара,—ди Хәп-җамал
әби,—
Көчең күрсәт тасма телеңнән...
Акыл җитсә,
Акыллы эш булса,
Бик мәслихәт, бик хуп күрермен.

Шуннан инде, безнең Гайҗан бабай
Чал мыекны җайлап бөтереп,
Дөнья күргән каеш түбәтәйне
Егетләрчә артка чигереп,
Борчак хәтле шикәр кисәгесен
Тел очында гына йөздереп,
Биш бармакка куеп чынаягын,
Чәйнең тәмен тәнгә сеңдереп,
Бая башлап киткән тәмле сүзен,
Дәртле сүзен дәвам иттерде:

— Ил, — мин әйтәм, — исең
китәр, карчык,
Күтәрелде ташкып шикелле.

Немчураны — кара бәчураны —
Чәйнәп ташлар өчен ашкына.
Егетләрен биреп кенә калмый,
Бар малын да илгә тапшыра.

Һәркем шешә саклык янчыгын,
Без нишләрбез икән, карчыгым?
Әгәр,—мәйтәм,—без дә синең белән
Ният итсәк шундый зур эшкә —
Бер самолет ясаттырып бирсәк,
Малаебыз Габдель-Котдускә?

Ул кагырас хәзер летчик безнең,
Шәп егет, дип үзен язалар,
Немчураны бомбылаган чакта
Сәләтенә хәйран калалар...

Я, карчыккай, нәрсә диерсең,
Ниндиерәк җавап бирерсең?

—Изге ният!
Бик тә әйбәт булыр,—
Ди Хәп-җамал әби куанып. —
Тик акчасын җүнәтербезме соң,
Кыйбаттыр бит хакы шул аның?

—Һи-и, кайгырма, — диде Гайҗан
бабай, —
Акчасын кына эрәт табарбыз,
Икәү бергә көн-төн эшләгәннең
Җимешләрен санап карарбыз.

— Алай булса —
Миннән фатиха!—дип,
Чәй янынннан әби кузгалды.
Һәм карты да чынаягын каплап,
Күзлек киде, җиңен сызганды.

Аннан инде, ак кәгазьләр алып,
Нидер яза,
Боза башлады,
«Һәй карасы!» диеп сөйләнгәләп,
Берлике бит буяп ташлады...

Шул чагында,
Сәлам бирә-бирә,
Килеп керде аның күршесе:
—Халык көтә, Гайҗан,
әйдә,—диде,—
Син колхозның олы кешесе,

Анда җыелыш,
Анда хикмәт, күрше,
Анда хәлләр бүген дуамал.
Хәзинәсен ачкан бөтен авыл:
Күктән яуган кебек ява мал.

Ә син монда
«Писер» булгансың да,
Кәгазь буяп борның тирләгән...
—Хәзер, хәзер! — диде Гайҗан
бабай,—
Бер генә сүз җайга килмәгән...

Оз... ламый язып бетте дә ул,
—Булды бу,—дип, салды күзлеген
Һәм киенеп, карчыгына дәште:
— Әйдә, — диде, — калма син
бүген!

II.

Җыелышка алар килү белән,
Халык бар да гөжләп җибәрде:
— Я ле, Гайҗан,
Соңга кала яздың,
Чират синдә—
Күрсәт җегәрне!

— Кордашларың яудырдылар
монда,
Кайсы өч мең,
Кайсы бишәр мең!

— Бишәр мең?
Пүчтәк икән,—диде Гайҗан
бабай, —
Мин янчыкны кинрәк шишәрмен!

Мин ярманы
Үзем күргән солдат,
Яхшы беләм аның этлеген,
Бирән авызын аның җимерү өчен,
Сугыш сорый күәт күплеген...

Халык кинәт тынып,
Телсез калды,
Сискәндерде аның сүзләре...
Гайҗан бабай шунда кәгазь алып,
Шытырдатып укып җибәрде:

— «Бөек кордаш, Иосиф Сталин,
Без, карчыгым белән икебез,
Кайнар сәлам сиңа җибәрәбез
Һәм бик озын гомер телибез.

Сәламнән соң кәлам диган кебек,
Янә сиңа шуны әйтәбез:
Безнең уллар тизрәк җиңсен
өчен —
Бер самолет бүләк итәбез.

Бар бердән-бер лачыныбыз безнең,
Габдель-Котдус аның исеме.
Гайрәтле татар егете ул,
Саф йөрәкле халык нәселе.

Безнең шушы уртак бүләгебез —
Корычканат—аңар бирелсен.
Ул күкләрдә йөзеп шуның белән,
Немчураның көлен китерсен.

Син башлаган җиңү шатлыгыннан
Күтәрелде бүген кин күңел:
Җир-суыбыз тазартылсын өчен,
Мал да безнен, җан да җәл түгел!

Гадел хезмәт белән тапканыбыз
Икебездән бердәй тиң булсын—
Ат җигәм дә таңда,
Госбанкка
Тапшырам мин илтеп
Йөз мең сум».

III.

Халык дәррәү дулкынланып китте,
Җир селкетеп аңар кул чапты:
— Ай-яй, картлач! —
Диде карты-яше,
— Йөз мең сум!—дип, бар да
шак-катты.
Таңга кадәр шаулап торды
җыелыш,
Кыр казлары гаңгылдашкандай.
Агылдылар меңнәр,
Инеш-елга
Ярларыннан чыгып ташкандай:

Кайсы—танк ясатам—дип,
Кайсы—пушка койдырам—дип,
Кайсы—сугыш ятимнәрен
Тәрбиялим—туйдырам—дип;
Мин—миномет эшләтәм—дип,
Мин—пулемет җибәртәм—дип,
Кабат-кабат халык өсти торды,
Калышмады бере-береннән.
Явыз дошман җиңелүен,
Һәркем
Теләп иде чын-чын күңелдән!

Ш. МАННУР.

ХАЛЫККА КИҢ КУЛЛАНУ ТОВАРЛАРЫН КҮБРӘК БИРИК

С. ШӘРӘФИЕВ
ТАССР Совнаркомы председателе урынбасары

Сугыш вакыты шартлары урындагы чимал һәм отходлардан киң куллану товарлары җитештерүне бөтен чаралар белән киңәйтүне таләп итә. Ләкин бу өлкәдә булган бик зур мөмкинлекләр бездә һич тә җитәрлек файдаланылмый әле. 1942 нче елда күп кенә промышленность предприятиеләре һәм промкооперация артельләре киң куллану товарлары эшләп чыгару планын үтәмәделәр һәм, нәтиҗәдә, халыкка 70 миллион сумлык күләмдә товар биреп җиткерелмәде. Лесзаг тресты (элекке управляющие иптәш Синдячкин) һәм Наркомлес (иптәш Коровин) предприятиеләре еллык планның яртысы чамасын гына үтәделәр. Промкооперация системасы да канәгатьләнерлек эшләмәде.

Кайбер наркомат һәм кооперация системасы җитәкчеләренең һәм шулай ук җирле совет башкарма комитетларының мәсьәләгә җиңелчә карашлары нәтиҗәсендә, электә җитештерелеп килгән байтак товарлар хәзер бөтенләй производстводан төшеп калганнар.

Мәсәлән, 23 райпромкомбинат буенча гына да 108 төрле изделие эшләп чыгару туктатылган. Әтнә райпромкомбинаты балта, дага һ. б. кебек әйберләрне хәзер бөтенләй эшләми, ә элек алар анда күпләп эшләнә иде. Промкооперация артельләренең дә күпчелегендә шундый ук хәл.

Киң куллану товарлары ассортиментын киметмәскә, ә киресенчә, арттырырга, бу өлкәдә киң инициатива күрсәтергә кирәк. Бу яктан Разнопромсоюз артельләре яхшы эшли (Президиум председателе иптәш Газизуллин). Алар 1942 нче елда 21 исемдә яңа төр продукция эшләп чыгаруны үзләштергәннәр. Ремонтпромсоюзның «Большевик» артеле, Разнопромсоюзның «Культпром» артеле, Металлопромсоюзның «Сталь» артеле, Леспромсоюзның «Һөнәрче» һәм «Труд» артельләре һ. б., Казан шәһәр промкомбинаты, Чистай галантерея фабрикасы, Чаллы, Куйбышев, Питрәч райпромкомбинатлары, Ютазы азык комбинаты яхшы эшлиләр һәм ассортимент буенча планнарны арттырып үтиләр, яңа төр товарлар эшләп чыгаруны үзләштерәләр.

Билгеләнгән ассортиментлар буенча быел планнарны үтәү һәм арттырып үтәү өчен, яңа төр продукцияләр эшләп чыгаруны үзләштерү өчен барлык предприятиеләр дә бу алдынгылардан үрнәк алырга тиешләр.

ТАССР Халык Комиссарлары Советы, күптән түгел, 1943 нче елда киң куллану товарлары җитештерү планын раслады. Дәүләт промышленносте предприятиеләре җирле чималдан 24.103 мең сумлык, кооперация системасы 145 миллион сумлык киң куллану товарлары һәм азык продуктлары эшләп чыгарырга тиешләр. Болардан тыш, сәүдә оешмалары җирле чималдан 20 миллион сумлык товар бирергә тиешләр.

Бездә чимал һәм материаллар җитәрлек. Арба, тәгәрмәч, чана, дегет, мебель агач савыт-саба һ. б. җитештерү өчен республикабызда урман байлыгы зур. Бу байлыктан тулысынча файдаланып, быел 32.000 чана, 9.300 арба, 32.500 стан тәгәрмәч ярты миллионнан артык агач кашык һ. б. эшләнергә тиеш. Урыннардагы төрле балчыклардан файдаланып, 1.200.000 литр сыйдырышлы балчык савыт-сабалар эшләнергә тиеш.

Быел аяк киемнәре эшләп чыгаруны нык кына арттыру күздә тотыла. Моның өчен күн һәм аяк киеме промышленносте отходларыннан киң файдаланырга кирәк. Аяк, өс-баш киемнәрен һәм төрле көнкүреш әйберләрен ремонтлау көчәйтелергә тиеш. Моның өчен яңадан 150 мастерской ачыла.

Планда билгеләнгән мех әйберләр (11.238 мең сумлык), трикотаж бельe, оек, оекбаш, шулай ук кер сабыны (850 тонна) һ. б. киң куллану товарларын күпләп җитештерү өчен бездә бөтен мөмкинлекләр бар.

Җирле чималдан азык продуктларын мул итеп җитештерү—гаять әһәмиятле бурыч. Быел яшелчә киптерү өчен өстәмә рәвештә 12 цех, мальтоза эшләү буенча—8, сироп эшләү буенча—4, алкогольсез эчемлекләр җитештерү буенча —7 цех оештырыла. Район азык промышленносте быел 400 тонна тозлаган яшелчә һәм 75 тонна киптерелгән яшелчә бирергә, 100 тонна мальтоза һ. б. азык продуктлары җитештерергә тиеш. 1.253 тонна гөмбә һәм кыргый җиләк-җимеш әзерләнергә, 5.760 баш дуңгыз симертелергә, 1.550 тонна балык тотылырга тиеш һ. б.

Җирле азык промышленносте өчен үз чимал базасын булдыру турында ныграк кайгыртырга кирәк. Ярдәмче хуҗалыклар оештырырга, алардан югары уңыш алу өчен көрәшергә, бигрәк тә витаминлы һәм шикәрле культуралар чәчүне киңәйтергә кирәк. Каен һәм өрәңге агачларыннан сок алуны оештыру бик файдалы эш. Бу—шикәрне алмаштыра торган бик яхшы продукт. Моны оештыру артык кыен эш тә түгел: 30 тонна сок бирә алырлык урман участогында эшләү өчен 10 кеше җита.

Халык өчен киң куллану товарлары һәм азык продуктлары җитештерү буенча билгеләнгән планны үтәү һәм арттырып үтәү өчен бездә бөтен мөмкинлекләр бар. Барлык тик работникларның эшлекле инициатива күрсәтүләре һәм булган җитешсезлекләргә, борыла алмаучылыкка каршы нык көрәш алып барулары кирәк. Урыннардагы партия һәм совет оешмалары киң куллану товарлары эшләп чыгару, җирле чималдан киң файдалану, кадрлар әзерләү өлкәсендә актив эш алып барырга, предприятиеләргә булышлык һәм җитәкчелек итәргә тиешләр.

Сугыш чорында халык өчен киң куллану товарларын мул итеп җитештерү—фронт өчен өстәмә материаль ресурслар булдыру дигән сүз, немец-фашист илбасарларны тизрәк тар-мар итү эшенә турыдан-туры булышу дигән сүз.

БЕРЕНЧЕ МАЙ АЛДЫ ЯРЫШЫ

Стахановчы вахтада

Цехком председателе Ельшин булган цех 17 нче мартта стахановчы вахтага басты.

Вахтаның беренче көннәрендә үк аерым стахановчылар эшләп чыгарышның югары күрсәткечләрен бирделәр. Токарь Федоров 17 нче мартта заданиене 181 процентка, 18 нче мартта—200 процентка, ә 19 нчы мартта—364 процентка үтәде. Токарь Смирнов 18 нче мартта норманы 300 процентка үтәгән булса, икенче көнне 375 процентка үтәде.

Цехта Май алды ярышы алдынгыларыннан токарь Молчанов, шлифовщик Котько, слесарьлардан Данилов, Савельев, Родионов иптәшләр сменага 3 әр норма бирәләр.

Һөнәр училищесы укучыларыннан Крайнов, Ваик, Әхмәтов иптәшләр стахановчы вахтага басканга кадәр нормаларны үтәмиләр иде. Хәзер инде, стахановча вахтага басып эшли башлагач, 18 нче мартта иптәш Крайнов үз нормасын—145 процентка, Әхметов—125 процентка, Ваик—120 процентка үтәделәр. Цех тулы килеш норманы 17 нче мартта—168 процентка, 18 нче мартта — 174 процентка, 19 нчы мартта—189 процентка үтәде.

Рәсемдә: Н-че заводның стахановчы фрезеровщигы иптәш М. С. Мостафин. Ул айлык заданиеләрне 250—260 процентка үти.
И. Папков фотосы.

Нормаларын арттырып үтиләр

Чистайдагы күн заводының утиль цехы планны системалы рәвештә диярлек 200 процентка үтәп бара. Стахановчылардан Вафина һәм Захаровалар икешәр—өчәр норма бирәләр. Сандал цехыннан Гайнуллина, Нәҗметдинова һәм Җәләева иптәшләр көнлек нормаларын 180 процентка кадәр җиткерәләр. Бу цех һәркөнне 130—150 процент үтәлеш бирә.

Яшьләрнең үрнәк эш[е]

Н-че заводның ремонт-механи[к] мастерскоенда март башлары[н]... яшь слесарьлардан махсус бригада төзелгән иде. Бу бригада составына кергән 10 иптәшнең барысы да һөнәр училищеларын тәмамла[п] производствога яңа гына килг[ән] яшь үсмерләр. Бригадада ста[ха]новчы слесарь иптәш Га... җитәкчелек итә.

Яшьләр бригадасы, Беренче Май алды ярышына кушылып, югары басымлы насослар мастерскоенда әзерләнә торган станинаны яхшы сыйфатлы итеп эшкәртергә йөкләмә алган иде. Яшьләр үз сүзләрен үтәделәр: тапшырылган задание хәзер тәмам төгәлләнде инде. Б[у] эштә бригаданың һәрбер члены смена нормаларын 120—130 процент итеп үтәде. Хәзер алар з[а]вод совхозы культиваторлары өчен, махсус чертежлар буенча бик катлаулы детальләр әзерләү өстендә эшлиләр.

Яшьләр бригадасы шулай б[ик] тырышып эшли һәм, практик в[акыт]та, яхшы өйрәтүче кулы астында бай производство тәҗрибәсе а[ла]...

ЯЗГЫ ЧӘЧҮГӘ ӘЗЕРЛЕК БУЕНЧА ФРОНТ АЙЛЫГЫ

ЧӘЧҮНЕҢ УҢЫШЛЫ ҮТҮЕН ТАРТУ КӨЧЛӘРЕ ХӘЛ ИТӘЧӘК

АТЛАРНЫ ҺӘМ МӨГЕЗЛЕ ЭРЕ ТЕРЛЕКЛӘРНЕ КЫР ЭШЛӘРЕНӘ ӘЗЕРЛӘҮГӘ ҖИТДИ ИГЪТИБАР БИРЕРГӘ, АЛАРДАН ТУЛЫСЫНЧА ФАЙДАЛАНУНЫ ТӘЭМИН ИТӘРГӘ!

Колхозларның орлык фондына

Совет патриотлары взносы

73. **Мөбарәков Д.**—Саба районы, «Якты юл» колхозы члены—12 пот ашлык бирде.

74. **Салахова Б.**—Баулы районы, «Урал» колхозы члены, фронтовик хатыны—6 пот ашлык һәм 12 пот бәрәңге бирде.

75. **Әхмәтвәлиев Г.**—Баулы районы, «Урал» колхозы члены—15 пот ашлык һәм 3 пот бәрәңге бирде.

76. **Касаков И.**—Кукмара районы, «Әзлән» колхозы члены—21 пот ашлык бирде.

77. **Ермаков Я.**—Кукмара районы, «Әзлән» колхозы члены—9 пот ашлык бирде.

78. **Давыдов Г.**—Кукмара районы, «Әзлән» колхозы члены—9 пот ашлык бирде.

79. **Сәгъдиев Н.**—Буа районы, Фрунзе исемендәге колхоз члены—12 пот ашлык һәм 12 пот бәрәңге бирде.

80. **Насибуллин З.**—Буа районы, Фрунзе исемендәге колхоз члены—10 пот ашлык һәм 10 пот бәрәңге бирде.

81. **Идрисов М.**—Буа районы, Фрунзе исемендәге колхоз члены—10 пот ашлык һәм 10 пот бәрәңге бирде.

„Байрак" колхозы атлары

«Байрак» колхозы (Шөгер районы) атлары кышны җылы абзарларда һәм тук үткәрделәр. Аларны тәрбияләү эше күпләргә үрнәк булырлык итеп куелган. Ат абзарлары иртән һәм кич чистартыла. Шулай ук атларны көн саен иртә белән кыргычлыйлар һәм щетка белән чистарталар.

Колхозның 56 аты бар. Алар барысы да группаларга бүленеп, ат караучыларга беркетелгән. Ай саен зоотехник тарафыннан ат караучылар белән төрле темаларга беседалар үткәрелә. Ат караучыларның барысы да үзара ярышалар. Ярыш йомгакламаларенең үтәлеше һәр айның ахырында тикшерелә. Ат караучыларга хезмәт көннәре атларның көрлегенә карап билгеләнә.

Шушы көннәрдә без бу колхоздагы уңышлы тәҗрибәләрне өйрәнү һәм аларны районыбызның башка колхозларына күчерү нияте белән махсус рейд үткәрдек. Рейд бригадасы чыннан да бу колхозда атларның торышын бик яхшы дип тапты. Шул ук вакытта без биредә күп кенә кимчелекләрне дә ачтык. Тупас азыкларның пешекләп ашатылмавын без бу колхоздагы төп кимчелек итеп исәплибез. Ат караучылар безнең киңәшкә нык әһәмият бирделәр һәм моннан соң тупас азыкларны пешекләп ашатырга булдылар.

Хәзер биредә атларны язгы чәчүгә әзерлиләр. Көчсезрәк атлар аерым тәрбиягә куела. Сбруйлар һәр атка карата аерым яраклаштырыла.

Хәеров, Галиева һәм Садретдинов иптәшләр карый торган атлар бигрәк тә яхшылар. Аларны күргән һәр кеше сокланмый кала алмый.

Хәбәрчеләр: **КӘБИРОВА, БУЛАТОВА.**

Икърар итү белән җир сөреп булмый, иптәш Орлов

Җанлы тарту көчләреннән тулысынча һәм дөрес файдаланмау нәтиҗәсендә, үткән елны Зәинский районы тунга сөрү планын бары 34 процентка гына үтәде. Бу хәл, үз-үзеннән билгеле, быелгы язгы кыр эшләрен шактый катлауландыра һәм кыенлаштыра. Мәсәлән, Ворошилов исемендәге колхозда язгы кыр эшләре вакытында һәр атка уртача 18,5 гектар, «Кызыл Шәрык» колхозында 15,2 гектар җир эшләргә туры киләчәк. Районның күп кенә башка колхозларында да атка нагрузка әнә шулай зур.

Нишләргә соң? Моннан котылу юлы бармы? Әлбәттә, бар. Беренчедән, атлардан тулысынча файдалануны оештырырга, икенчедән, мөгезле эре терлекне җигүле эшкә өйрәтергә кирәк. Хәзерге көндә моның әһәмияте аеруча зур. Район җир бүлеге мөдире иптәш Орлов моны үзе дә инкар итми. Әйе, мөгезле эре терлекләрне кыр эшләренә өйрәтү безгә язгы чәчүне кыска срокларда үтәүгә зур ярдәм итәчәк, ди ул. Район җир бүлеге бу турыда колхозларга план да җиткергән. Бу план буенча районда быел язгы чәчүгә кадәр 250 баш мөгезле эре терлек кыр эшләренә өйрәтелергә тиеш. План зур түгел. Аны һәрбер колхозга бүлгәндә уртача 3 баштан да кимрәк туры килә. Ләкин район җир бүлеге бу турыда план җиткерү белән канәгатьләнгән.

Кайбер колхоз җитәкчеләре иптәш Орлов кебек үк бу чараны бик әһәмиятле дип исәплиләр. Әмма практик эшкә килгәндә хәл бөтенләй киресенчә. Мәсәлән, «Ворошиловец» колхозы председателе иптәш Петрова сыерларны эшкә өйрәтүгә язгы чәчү җиткәч кенә керешергә исәп тота. «Кызыл Кадык» колхозы председателе иптәш Кәлимуллин хәтта бу турыда уйлап та караганы юк.

Мөгезле эре терлекләрне җигүле эшкә өйрәтү турында лыгырдап йөрүне ташларга, кичекмәстән конкрет эшкә керешергә кирәк.

А. ВӘЛИЕВ.

ФРОНТОВИК НАКАЗЫ ҮТӘЛӘ

Колхозның ат караучысы иптәш Заһидуллин фронтка киткән вакытта хатынына:

— Мин караган атлар элеккечә көр булсыннар, ару-ны белмәсеннәр. Син, Наһар, аларны үзең кара. Син бит минем атларны ничек тәрбияләвемне беләсең,—диде.

Наһар иптәш Заһидуллина фронтовик иренең наказын үти. Менә икенче ел инде ул атларны яхшы итеп тәрбияли. Аның атлары элеккечә таза һәм чыдамлылар.

Хәдичә Нәбиуллина белән Бәхет Басирова иптәшләр дә фронтовик хатыныннан калышмыйлар. Алар кыш көне ат карыйлар, яз һәм җәй көннәрендә үзләре тәрбияләгән атларның кайберләре белән кыр эшләрен башкаралар: сабан сөрәләр, җир тырмалыйлар. Бу иптәшләрнең дә атлары яхшы хәлдә. Алар атны җигеп китүчеләрдән эш урынында атларны яхшы тәрбияләүне таләп итәләр. Бирелгән азыкны ашатмау, кыйнау фактлары булганда бу турыда правлениегә хәбәр итәләр. Шулай тырышып эшләү нәтиҗәсендә, аларга беркетелгән атлар кышны яхшы үткәрделәр. Көрлекләрен югалтмадылар.

М. ШАКИРОВ.

ДЕКАДА УҢЫШЛЫ ҮТӘ

Куйбышев районы колхозларында чәчүлек орлык туплау декадасы зур оешканлык белән бара. Чәчүлек мәйдан өчен кирәкле орлыкның бер өлешен колхозчылар үз хуҗалыкларындагы запас ашлык белән тулыландырырга булдылар. «Красный борец» колхозы члены иптәш Ершов 25 пот ашлык биреп:

— Минем ике улым фронтта. Алар илгә җиребезне мәңгүн дошманнан чистарту өчен тормышларын да кызганмыйча сугышалар. Мин дә үземнең байлыгымны кызганмыйм. Ул ватанымны баетсын,—диде.

Биредә ике көн эчендә орлык өчен 7 центнер ашлык тупланды. «Тукай», «Верный путь», «Весна» колхозларында да декада уңышлы бара. Иптәш Шмырина 1,5 центнер, Шадрин, Савельева, Дубровин, Орешкин иптәшләр 1 әр центнер ашлык биреп тордылар.

А. КӘРИМУЛЛИН.

АТЛАР КӨР

Кайбер колхозларның ат караучылары атларның начар хәлдә булуын, көчле азык аз, тупас азык белән генә аларны ничек көрәйтәсең, дип аңлатырга тырышалар. Зарланып йөрү урынына ничек итеп азыкны эшкәртеп, йомшартып ашату турында уйламыйлар.

«Уңыш» колхозының (Тәкәнеш районы) ат караучылары болай зарланып гомер үткәрүнең урынсыз икәнен яхшы аңлыйлар. Шуңа күрә дә, бу колхозның атлары көр һәм чыдамлы. Менә ат караучы иптәш Гайнуллина. Ул иң әлек саламны яхшылап турап вак-лый, аннан соң аны җылы су белән пешекләп йомшарта. Атларның бирелгән азыкны чәчеп бетермәүләрен күзәтеп тора. Улакларны һәрвакыт чиста тота. Атларга төнлә дә икешәр тапкыр су эчертә. ВКП(б) Өлкә Комитетының IX пленум карарларын өйрәнгәндә ул үзе карый торган атларның көрлеген арттыру өчен бик нык тырышырга сүз бирде.

Колхозда өлкән ат караучы иптәш Вәлиуллинның да хезмәте зур. Ул атларны карауны яхшы оештыру чараларын күреп тора. Ат караучылардан аларга беркетелгән атларның көр һәм исән-сау булуларын таләп итә. Биредә камыт-ыңгырчак тигән атлар юк. Колын салу фактлары да булмый. 1942 нче елда 80 баш ат бар иде. Хәзер аларның саны 85 кә җитте һәм шуның өстенә колхоз Кызыл Армиягә дә 12 ат тәрбияләп бирде.

Х. ФӘЙЗИ.

КОЛХОЗЛАР ӨЧЕН КАДРЛАР

Биектау район җир бүлеге кырчылык бригадалары бригадирлары әзерләү өчен Тукай исемендәге колхозда ике атналык курс оештырды. Яшелчә бригадалары бригадирлары әзерләү өчен «Искра» колхозы янында ачылган курс та үзенең эшен уңышлы дәвам иттерә. Умартачылар әзерләү өчен «Смычка» колхозы янында да курс ачылды.

Д. СКВОРЦОВ.

Казан парфюмерия фабрикасының 2 нче номерлы конвейер бригадасы бригадиры иптәш Беленькая үз бригадасының эшен яхшы оештырды. Аның бригадасы 1943 нче елның 2 айлык заданиесен 20 нче февральгә үтәде һәм хәзер көнлек заданиене 150 процент үтәп бара. Рәсемдә: иптәш Беленькая конвейер янында.

К. Тахтеев фотосы.

Яшелчәдән мул уңыш алу өчен

Шушы көннәрдә Казан химия-технология институты бинасында Молотов районы хезмәт ияләренең җыелышы булып үтте. Җыелышта индивидуаль һәм коллектив яшелчә бакчаларында язгы чәчүгә әзерлек турында хезмәт ияләре депутатларының Молотов район Советы башкарма комитеты председателе иптәш Курочкинның докладын тыңланды.

Шәһәр хезмәт ияләре арасында индивидуаль яшелчә бакчачылыгы белән шөгыльләнүчеләрнең саны торган саен арта бара. Үткән елны Молотов районында 42 оешмада эшләүчеләрдән 6.000, нән артык кеше үзләренә билгеләнгән җирләргә бәрәңге һәм яшелчә утырткаштар иде. Быел аларның саны 24.000 гә җитә. Индивидуаль яшелчә бакчалары өчен бу районда янадан 60 гектар җир билгеләнде.

Күп кенә оешмалар язгы чәчүгә канәгатьләнерлек әзерләнәләр. Казан педагогия институты, психиатрик больница һәм кайбер предприятиеләрнең җитәкчеләре бу өлкәдә аеруча яхшы эшлиләр. Алар чәчүлек бәрәңге һәм бәрәңге кисентеләре, көл һәм авыл хуҗалыгы инвентаре әзерләүне оештырганнар. Шул ук вакытта кайбер оешмаларның җитәкчеләре һәм профсоюз оешмалары бу эшкә тиешенчә әһәмият бирмиләр. Микоян исемендәге фабрикада, «Строитель» комбинатында «Динамо» фабрикасында һәм башка кайбер оешмаларда чәчүлек орлык һәм авыл хуҗалыгы инвентаре әзерләү оештырылмаган. Бу оешмаларның җитәкчеләре чәчүлек орлыкны үзәк фондтан алуны көтеп торалар, хезмәт ияләренең инициативасы белән, чәчүлек бәрәңге, ашлама һәм инвентарь әзерләү чараларын күрмиләр. Бу җитешсезлекләрне кичекмәстән бетерергә, язгы чәчүне тулы әзерлек белән каршы алырга кирәк.

Җыелышта авыл хуҗалыгы фәннәре кандидаты иптәш Демидович бәрәңге һәм яшелчәдән ничек югары уңыш алу турында бик файдалы киңәшләр бирде.

Җыелышта чыгып сөйләүче иптәшләр индивидуаль яшелчә бакчаларыннан уңыш алуда үзләренең тәҗрибәләре белән уртаклаштылар һәм бу эшне оештыруда булган күп кенә җитешсезлекләрне күрсәтеп үттеләр.

Җыелыш язгы чәчүне яхшы итеп үткәрү өчен күп кенә конкрет чаралар билгеләде.

Рәсемдә (сулда): Юдино районы, «Оборона страны» колхозының өлкән ат караучысы иптәш Евдокия Савина. Аның тырышлыгы һәм үз эшен намус белән башкаруы нәтиҗәсендә колхозның атлары язгы чәчүгә әзер. Уңда —шул ук районның «Комсомолец» колхозы зоотехнигы иптәш Мирошниченко сыерларны җигүле эшкә өйрәтә. Иптәш Мирошниченко 3 пар сыерны һәм бер үгезне язгы кыр эшләрендә файдалану өчен әзерләде инде.

К. Тахтеев фотосы.

АЗАТ ИТЕЛГӘН РАЙОННАРГА

Кукмара районының «Большевик» газетасы типографиясендә эшләүчеләр азат ителгән районнарга ярдәм итүдә актив катнашалар. Рәсемдә: типография работниклары азат ителгән районнарга җибәрү өчен әйберләр тапшыралар.

Х. Басиров фотосы.

Сталинград өчен тегү мастерское

Завком председателе урынбасары иптәш Кисарина булган Н-че заводның эшчеләре героик Сталинград шәһәрен һәм аның районнарын аякка бастыруда турыдан-туры ярдәм итү өчен бик күп төрле чаралар үткәрәләр.

Сталинградны аякка бастыру мәсьәләсе белән цехларда үткәрелгән җыелышларда катнашучы эшчеләр үзләренең бер көнлек хезмәт хакларын Сталинградка ярдәм фондына бирү турында бертавыштан карар кабул иттеләр.

5 нче производствода үткәрелгән җыелышта чыгып сөйләүче иптәш Фокина заводның барлык хатын-кызларын Сталинград хатын-кызларына ярдәм итәргә чакырып болай диде:

— Фашистик ерткычлар бәхетле тормышта яшәүче совет семьяларын юк итәргә теләделәр. Аларның бу явыз теләкләре үтәлмәде һәм беркайчан да үтәлмәс. Ерткычлар коллыгыннан азат ителгән районнар тормышка кайтарылалар. Без, Сталинградны аякка бастыру өчен төзү материаллары, станоклар һәм җиһазлар җибәрү белән бергә, совет семьяларының яңа тормышын төзүче Сталинград хатын-кызларына йорт әйберләре һәм кием-салымнар белән дә ярдәм итәргә тиешбез.

Иптәш Фокина үзе 12 пычак һәм 12 чәнечке бирде.

Хәзер цехларда кием-салымнар һәм йорт кирәк-яраклары җыю эше дәвам итә.

Завод дирекциясе Сталинград шәһәренә җибәрү өчен 160 мең сумга төшереп бер тегү мастерское җиһазлады.

Завод, төзелештә эшләү өчен, Сталинградка 3 кеше җибәрә.

Ф. СӘГЪДИЕВА.

ФРОНТОВИК ЯЗУЧЫ ХАТИП УСМАНОВ БЕЛӘН ОЧРАШУ

Фронт газеталарының берсендә эшләүче язучы иптәш Хатип Усманов вакытлыча Казанга кайтты. Совет язучылары союзында шушы көннәрдә аның белән дусларча очрашу үткәрелде. Җыелган язучыларга иптәш Усманов фронт истәлекләрен сөйләде һәм «Йөрәк ялкыны» исемле яңа әсәрен укыды.

Җанлы фикер алышуларда катнашкан язучылар (Г. Разин, Г. Кашшаф, Х. Хәйри, И. Туктар, Г. Иделле һ. б.) әсәргә югары бәя бирделәр. Героик фронт һәм андагы җанлы кешеләр турында, явыз дошманны тар-мар итү, илебезнең бәхетле, шатлыклы тормышын саклап калу эшендә үз тормышларын да кызганмаучы безнең сугышчыларыбыз, гүзәл яшьләребез турында авторның бу яңа әсәре көчле дулкынлану хисләре һәм югары художество теле белән сөйли.

ГЕРМАНИЯ ШӘҺӘРЛӘРЕН БОМБАГА ТОТУНЫҢ НӘТИҖӘЛӘРЕ ТУРЫНДА ГИТЛЕР ГАЗЕТАЛАРЫ

ЖЕНЕВА, 25 март. (ТАСС). Гитлер газеталары, Эссен һәм Мюнхен шәһәрләрен бомбага тоту нәтиҗәсендә бу шәһәрләрдә тормышның бөтенләй какшаганлыгын икърар итәләр. «Националь цейтунг» газетасы, бик пык җимерелүләр булу сәбәпле властьлар Эссен халкының бер өлешен Көньяк Германиягә күчерә башларга мәҗбүр булдылар, дип яза. Газетаның язуынча, шәһәрдәге барлык мәктәпләр, торак йортларга әйләндерелгән.

«Мюнхнер нейсте нахрихтен» газетасы Мюнхенга барудан тукталып торырга киңәш бирә, чөнки бомбага тотулар нәтиҗәсендә шәһәрдә коммуналь хуҗалык чыгырыннан чыккан.

СТОКҺОЛЬМ, 25 март. (ТАСС). Немецларның «Ангрифф» газетасының язуына караганда, охрана отрядлары җитәкчесе һәм Германия полициясенең начальнигы Гиммлер Германия шәһәрләрендә 23 сәгатьтән соң һәртөрле хәрәкәтне туктату турында боерык биргән. Боерык кичекмәстән үтәлергә тиеш.

Англиядә союзниклар илләре гражданнарын хәрби хезмәткә алу

ЛОНДОН, 25 март. (ТАСС). Англиянең информация министрлыгының белдерүенчә, союзниклар илләре гражданнары булган һәм армиягә чакырылу яшенә җиткән чит ил кешеләрен Англиянең корраллы көчләре (сапер корпусы) сафларында хәрби хезмәткә чакыру турындагы закон 1 нче апрельдән гамәлгә керә. Бу закон 1900 нче елның 1 нче июле белән 1925 нче елның июне арасындагы чорда туган Бельгия, Чех-Словакия, Греция, Голландия, Польша һәм Югославия гражданнарына кагыла. Хәрби хезмәткә барлыгы 10.000 чит ил кешесе алыначак.

Туниста сугыш хәрәкәтләре

ЛОНДОН, 25 март. (ТАСС). Рәсми рәвештә хәбәр ителүенчә, кичә Марет районында артиллериядән бик каты атыш башланган. Гафса районында Американың кечерәк частьлары уңышлы һөҗүм сугышлары алып барганнар. Макнасси участогында союзниклар гаскәрләре бераз алга киткәннәр. Авиация, дошманның җыелып тора торган гаскәрләрен, аэродромнарын һәм башка объектларын бомбага тотып, зур активлык күрсәткән. Һава сугышларында дошманның 10 самолеты бәреп төшерелгән.

ЛОНДОН, 26 март. (ТАСС). Рейтер агентлыгы союзникларның Төньяк Африкадагы штабының белдерүен тапшыра. Белдерүдә әйтелүенчә, 8 нче армия хәрәкәт итә торган районда Англия пехотасы бераз алга киткән һәм үзенең позицияләрен яхшырткан. Гафса һәм Макнасси секторларында сугыш хәрәкәтләре артык көчле булмаган. Дошман берничә тапкыр җирле әһәмияте булган атакалар ясаган. Төньяк секторда сугыш хәрәкәтләре бераз активлашкан.

Германиянең югалтулары турында Швеция газеталары

СТОКҺОЛЬМ, 24 март. (ТАСС). Германиянең югалтулары турында Гитлер белдергән көлке саннарга Швециянең күп кенә газеталары ачыктан-ачык уйдырма саннар, дип карыйлар. Мәсәлән, «Социал-демократен» газетасы болай дип яза: «Польшада, Даниядә, Норвегиядә, Бельгиядә, Голландиядә һәм Балканда хәрби «прогулкалар» вакытында Германиянең югалтулары аз булган булса, соңыннан инде хәл үзгәреп китте... Русларның кышкы һөҗүме һәм бигрәк тә Сталинград янында чолганып алынган 6 нчы армиянең юк ителүе Германия армиясе өчен бик авыр булып чыкты».

«Гетеборгс хандельстиднинг» газетасы болай дип яза: «Әгәр дә Германия чыннан да бары ярты миллион гына кеше югалткан булса иде, ул чагында фронт өчен солдатлар эзләп табу теләге белән хәзерге вакытта бөтен илне актарып чыгу, шулай ук чит илләрдән эшчеләр китертү кирәк булмас иде».

Швециянең позициясе турында түбәнге палатада сорау

ЛОНДОН, 24 март. (ТАСС). Рейтер агентлыгының хәбәр итүенә караганда, 19 немец солдаты утырган бер Германия самолетының Швеция җиренә төшәргә мәҗбүр булуы турында, шулай ук Германиянең хәрби транспорт самолетларының Швеция чиге аркылы очып үтүләре турында бүген түбәнге палатада сораулар бирелгән. Бу сорауларга җавап биреп, чит ил эшләре министры урынбасары Лоу, Англиянең Стокһольмдагы илчесенә бу фактларны тикшерергә һәм Швеция хөкүмәтеннән аңлату сорарга инструкцияләр бирелгәнлекне әйткән.

Татарстанда

— Актаныш районы финанс планын үтәү буенча республика күләмендә алдынгы районнардан санала. 1942 нче елда районда финанс туплау планы 150 процентка үтәлде. Район финанс бүлеге 1943 нче елның беренче квартал планын да срогыннан элек арттырып үтәде.

— Фронтовикларның семьяларына ярдәм күрсәтү буенча Казан мехкомбинатында оештырылган комиссия соңгы көннәрдә 900 гә якын фронтовик семьясының материаль-көнкүреш хәлен тикшерде. 290 семья утын белән тәэмин ителде. Фронтовик семьяларына төрле промтоварлар алу өчен 2.016 ордер өләшенде. Күп кенә фронтовикларның балаларына мех тышлы тун, мех оек, бүрек, белье һәм киез итекләр бирелде. Прокофьева, Катапова һәм Абросимова иптәшләр яңа квартираларга күчерелделәр.

—«Спартак» комбинатының эшчеләр коллективы дошманнан азат ителгән районнарга җибәрү өчен эш вакытыннан тыш 150 килограмм кадак әзерләделәр. Шуның өстенә эшчеләр бик күп төрле йорт кирәк-яраклары җыйдылар.

Медицина работникларының район киңәшмәсе

Саба районында эшләүче медицина работникларының шушы көннәрдә район киңәшмәсе булып үтте. Киңәшмәдә хирургия авырулары турында доктор Каржавин һәм «Яңа медикаментлар һәм аларны куллану» дигән темага аптеки мөдире Кәвиева иптәшләрнең докладлары тыңланды. Киңәшмә районда йогышлы авыруларга каршы көрәш буенча күп кенә профилактик чаралар билгеләде.

СУД

ДӘҮЛӘТ МИЛКЕН УРЛАУЧЫЛАР

Н-че заводның эшчеләрне тәэмин итү бүлеге базасында мөдир булып эшләгән Салих Әшрәфҗанов, куст директоры Петр Степанов һәм шофер Гомәр Хәйруллин, үзара килешеп, төрле азык продуктлары урлау белән шөгыльләнгәннәр. Алар үзган елның көзендә 150 килограмм май, 2 капчык шикәр, 70 килограмм селедка урлаганнар. Хәдичә Зарипова һәм Маһирә Фәхретдинова дигән хатыннар урланган бу продуктларны спекуляция бәясеннән саттканнар.

Бу җинаятьче группаның эше шушы көннәрдә иптәш Иванов председательлегендә Татарстан Верховный Судында каралды. Әшрәфҗанов, Степанов һәм Хәйруллин 10 ар елга төрмәгә ябылу һәм җәза срогын тутырганнан соң сайлау-сайлану хокукыннан 5 елга мәхрум ителүгә, Зарипова һәм Фәхретдинова 5 әр елга ябылу хөкем ителделәр.

Суд шулай ук урланган продуктларны базар бәясе белән исәпләп гаепләләрдән түләтергә хөкем итте.

Җаваплы редактор И. ҮЗБЕКОВ.

ШӘҺӘРДӘ АТ КОРЧАҢГЫСЫН БЕТЕРҮ ЧАРАЛАРЫ ТУРЫНДА

КАЗАН ШӘҺӘР СОВЕТЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ КАРАРЫ

ТАССР Совнаркомының 1942 нче ел, 4 нче февраль, 48 нче номерлы карарын үтәү йөзеннән хезмәт ияләре депутатларының Казан шәһәр советы **карар бирде:**

1. Шәһәр җир бүлегенә һәм атлары булган учреждениеләрнең һәм предприятиеләрнең җитәкчеләренә, хуҗалыкларга беркетелгән ветеринария персоналы ярдәме белән, ә алар булмаган урыннарда—шәһәрнең ветеринария-дәвалау учреждениеләре аркылы, 1943 нче елның 1 нче маена кадәр, кимендә айга ике тапкыр, барлык атларны тикшереп чыгарга мәҗбүр итәргә.

2. Предприятиеләрнең һәм учреждениеләрнең җитәкчеләрен түбәндәгеләргә мәҗбүр итәргә: а) корчаңгы белән авырган барлык атларны изоляцияләргә һәм бөтенләй сәламәтләнеп җиткәнгә кадәр эштән азат итеп дәваларга; б) ат сараен, сбруйларны, ат карау әйберләрен дезинфекцияләргә; в) авырган атларны, шулай ук корчаңгы белән авыруда шикле булган атларны карау өчен махсус кешеләр билгеләргә, аларны эш киеме белән тәэмин итәргә, сәламәт атлар белән аралашуны кискен рәвештә тыярга; г) атларны һәркөн чистартуга ныклы контроль куярга, чистартылмаган атларны җигеп чыгуга юл куймаска; д) һәрбер атка сбруйлар һәм карау әйберләре беркетергә һәм номерлар куярга; е) атларны районнарга җибәргәндә аларның сәламәтлеге турында һәм хуҗалыкта йогышлы авыруларның булмавы турында ветеринария таныклыгы биреп җибәрергә, ә районнардан кайткан атны һәм сбруйларны мәҗбүри рәвештә профилактик газлау яки ветеринария-санитария эшкәртүе аша үткәрергә; ж) районнардан килгән атларның шәһәр транспорты ишекалларына һәм ат абзарларына керүенә юл куймаска; з) районнардан шәһәргә эшкә килгән барлык атларны бары тик ветеринария белешмәсе булганда гына, шулай ук аларда корчаңгы һәм башка авыруларның булмавы турында шәһәрдәге ветеринария-дәвалау учреждениеләренең бирсеннән белешмә булганда гына эшкә җибәрергә.

3. Колхозчылар йорты ишекалдына һәм Казанга килгән атлар тукталып торган башка урыннарга ветеринария-дезинфекция станциясе көче белән кимендә айга ике тапкыр мәҗбүри профилактик дезинфекция ясарга. Корчаңгы авыруы һәм башка йогышлы авырулар белән авыруда аз гына шикле булган атларны да мондый тукталу урыннарына җибәрмәскә; шулай ук андый атларны урамда тотып алырга һәм шәһәрнең ветеринария-дәвалау учреждениеләренә җибәрергә.

4. Бу карарның үтәлешенә контроль ясауны шәһәр җир бүлегенең ветеринария күзәтчелегенә һәм милициягә тапшырырга.

5. Бу карарны үтәмәүче кешеләрне 100 сумга кадәр штраф түләтү яки бер айга кадәр срок белән хезмәт-төзәтү эшенә җибәрү белән җавапка тартырга; ә аеруча усал ният белән булган очракларда—каты җавапка тартырга.

Казан шәһәр советы башкарма комитеты председателе **Д. ТЫШКЕВИЧ.**

Казан шәһәр советы башкарма комитеты секретаре **П. МОРОВ.**

ТЕАТРЛАРДА ҺӘМ КИНОЛАРДА

Татар дәүләт опера һәм балет театры. 31 нче мартта — «ИЛЬДАР».

Зур драма театры. Бүген — «УКРАИНА ДАЛАЛАРЫНДА».

Яшь тамашачылар театры. Бүген көндезге бер сәгатьтә һәм кичке 7 сәгатьтә—КОНЦЕРТ.

Дәүләт циркы. Бүген 3 бүлектә ЗУР ЦИРК ТАМАШАСЫ. Кич 8 сәгатьтә башлана.

Татарстан дәүләт филармониясе 28 нче мартта Менжинский исемендәге клубта сәнгать мастерлары катнашы белән ЗУР КОНЦЕРТ. 8 сәгать 30 минутта башлана.

«Электро» — яңа документаль фильм—«СТАЛИНГРАД». **«Унион»** көндез һәм кич—«МОРЯК КЫЗЫ». **«Пионер»**—көндез—«РУСЛАН һәм ЛЮДМИЛА» һәм «БОКСЕРЛАР», кич—«МИНЕМ МӘХӘББӘТЕМ». **«Чатки»** көндез «ӘКИЯТЛӘР» һәм «ЧАПАЕВ», кич—«ФРОНТКА КОНЦЕРТ».

Редакциянең телефон номерлары: җаваплы редактор—73—27, Редактор урынбасары АТС 76—29, секретариат һәм авыл хуҗалыгы бүлеге 79—29, промышленность, транспорт, партия тормышы һәм хатлар бүлекләре 78—93, типография 36—60.

ПФ1088 «КРАСНАЯ ТАТАРИЯ» һәм «КЫЗЫЛ ТАТАРСТАН» издательствосының АЛЕКСАНДРОВ ИСЕМЕНДӘГЕ ТИПОГРАФИЯСЕ № Заказ 254 01